А. Г. ЯХИН

Әдәбият

1

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Әдәбият
А. Г. ЯХИН
1



А. Г. Яхин

Әдәбият

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
1 нче сыйныфы өчен дәреслек

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Тулыландырылган 2 нче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2009

УДК 373.167.1:821.512.145*01
ББК 84(2Рос=Тат)я71
Я89

Рәссамы *Алексей Мамаев*

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Шартлы билгеләр:

?! Сораулар һәм биремнәр

Иҗади эш

Яхин А. Г.

Я89 Әдәбият : Дүртьеллык башл. татар мәкт. 1 нче с-фы өчен д-лек / А. Г. Яхин.— Тулыл. 2 нче басма.— Казан : Мәгариф, 2009.— 119 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-7761-1930-9

ISBN 978-5-7761-1930-9

© «Мәгариф» нәшрияты, 2003
© «Мәгариф» нәшрияты, 2009, үзгәрешләр белән

ӘСӘРДӘ КАТНАШУЧЫЛАР

Бәхетле бала

Бәхетле шул баладыр,
кайсы дәрсенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олуг күрсә,
белергә кушканын белсә.

Сабакка калмаса соңга,
борылмый барса уң-сулга,
Уенга салмаса ихлас — менә бәхте аның шунда.

Кечеләргә итеп шәфкать,
үзеннән зурга юл бирсә,
Бәхетсезләрне кимсетми,
егылганнарга кул бирсә.

Габдулла Тукай

?! Бу шигырьдә күренеп торган катнашучы берәү генә. Ул — бәхетле бала. Дәресенә күңел бирүче, укытучысын хөрмәт итүче бала...

Шигырьдә күренеп тормый торган тагын ике катнашучы бар. Берсе — автор, Габдулла Тукай.

Габдулла Тукай бәхетле бала турында кемгә сөйли? Бала ни өчен бәхетле?

Гали белән Кәҗә

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.

Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

Габдулла Тукай

?! **1.** Шигырьне үз сүзләрегез белән сөйләгез. Мәсәлән: *Гали Кәҗә белән дус икән...* (Дәвам итегез.)

2. Катнашучыларны бергәләп табыйк.

Менә мондый бик матур сорау: автор ничек катнаша?

Гали Кәҗәгә печән биргәндә, автор — юк. Ничек булсын, авызына каптырганны ашаган Кәҗә вакыйгасында авторның уе да, хисе дә, шаяруы да катнашмый бит.

Ә менә Кәҗә рәхмәт әйткәндә бар. Чөнки Кәҗә рәхмәт әйтә алмый. Рәхмәтне аңа автор әйттерә.

3. Автор тагын безгә әйткән сүзе белән катнаша. Ул безгә ни ди?

Әсәрдә кешеләр дә, хайваннар да, кошлар да катнаша икән.

Гөлнар мәктәпкә бара

Кечкенә толымнарына
Ал тасмалар таккан ул.
Ә алдына кардан да ак
Алъяпкычын япкан ул.

Кулларына сумка белән
Чәчәк бәйләме тоткан.
Мәктәпкә соңга калмыйм дип,
Ашарга да онытткан.

Гөлнар киткәндә эндәште
Яраткан курчагына:
— Кулларымда әйбер бар шул,
Алалмыйм кочагыма.

Мин бүгеннән йөри башлыйм
Мәктәбемә укырга.
Син, мин киткәч, ник кайтмый дип,
Ямансулап утырма.

Мәрзия Фәйзуллина

Кыз ал тасма таккан, ак алъяпкыч япкан... (Дәвам итегез.)

Хәзер мәктәпкә баручы малай турында языгыз. *Яланбашлы, ак күлмәкле...* (Мәктәпкә килүче малайларны күз алдына китерегез дә дәвам итегез. Яки үзегез турында, яисә «малайлар менә болай киенергә тиеш...» дип языгыз.)

Гөлнарның мәктәпкә җыенуын, ничек киенгәнен кем карап торган?

Кара тавык, ак тавык

— Кара тавыклар акларына караганда булдыклырак була.

— Нигә алай дисең?

— Ак тавык кара күкәй сала алмый, ә кара тавык акны сала.

1. Искә төшерик әле: без нинди катнашучылар белән таныштык?

2. Биредә биш катнашучы бар. Табыгыз.

3. Кара тавыклар акларыннан булдыклыракмы? Ни өчен?

Балкый Фонтан

— Әй Чишмә, күр, ничек гүзәл бит мин,
Ә син алай түгел, талантсыз!
Балкый Фонтан күз яуларын алып,
Ә эчәргә суы яраксыз.

Нәҗип Мадьяров

Нәҗип Мадьяров шигырендә төп катнашучылар — Чишмә белән Фонтан. Башка әсәрләрдә багана, болыт, агач, тагын, тагын әллә ниләр катнашачак. Шуларның барысын бергә **предметлар** дип атыйк.

?! **1.** Чишмә белән Фонтанның төп аермасын табыгыз. Аерма табылгач, мактанган өчен Фонтанга җәза биреп була. Сез аңа нинди җәза бирер идегез?

2. Шигырьдә Фонтан кеше кебек сөйләшә, ә Чишмә кеше кебек тыңлап тора. Алар кешеләрме, Фонтан белән Чишмәме?

3. Фонтанга бәя бирү өчен, 9 нчы биттәге мәкальләрнең кайсысын сайлар идегез?

Мәкальләр

- Теле булмаса, күптән карга күтәреп киткән булыр иде.
- Чүлмәгенә күрә капкачы.
- Мактанганда бар, актарганда юк.
- Мактанчык—буш янчык.
- Сай су болганчык. Сай акыл мактанчык.
- Тыйнакның кулы эшләр, мактанчыкның теле эшләр.

Макай белән Акбай

Макай — чанада яткан,
Акбай — чананы тарткан.
Макай — мәктәптән качкан,
Акбай — букчасын капкан.
Макай — төнен йоклаган,
Акбай — аны саклаган.
Макай — батмый чак калган,
Акбай — аны коткарган.

Акбай — чирли башлаган,
Макай — аны ташлаган.
Акбай — салкында туңа,
Макай — җылыда куна.
Кочакладым Акбайны:
«Оныт,— дидем,— Макайны!»

Илдар Юзеев

?! **1.** Шигырьдә Макай белән Акбай катнаша. Ни өчен чана белән букча катнашмый?

2. Әсәрдә өченче катнашучы да бар. Кем ул? Аны шигырьдән табып күрсәтегез.

Тукта! Ник качасың?

Әллә төштә, әллә өндә,
Әллә кичен, әллә төндә —
Бара Сәгыйть урам буйлап,
Бик куркыныч уйлар уйлап:
«Килеп чыкса бер юлбасар
Йә хулиган — кая качар?»
Ишетә ул ят бер тавыш:
«Сәгыйть, кая китеп барыш?»
Аяклары тими җиргә,
Тотына ул йөгерергә.
Шүрләмәгән икән юкка:

Арттан тавыш: «Сәгыйть! Тукта!»
Ә монысы — тимәс кебек:
«Бездән куркып калгансыңдыр,
Хәл җый туктап, аргансыңдыр».
Һаман чаба, чаба Сәгыйть,
Хәлдән таеп ава Сәгыйть.
Куучылар ала урап,
Сәгыйть мескен ята елап:
«Ник кудыгыз, ник тоттыгыз?
Сез кемнәр? Ник куркыттыгыз?»
— Сорау биргәч, ник дәшмәдең?
— Хәл җый дигәч сөйләшмәдең.
— Туктамадың «Тукта!» дигәч.
— Егылдың, мин — Нокта килгәч.
— Безне артык дип уйлыйсың.
— Язган чакта ник куймыйсың
Сорау, өндәү, нокта, өтер?
Йәле, дәфтәреңне китер!
Сәгыйть торып утырган, ди.
Сүз биреп чак котылган, ди:
«Онытмамын һәр җөмләдә,
Көндезен дә һәм төнлә дә.
Яшәү рәхәт хата юкта.
Ялгышларга куям нокта».

Илдар Юзеев

?! **1.** Катнашучыларны икегә генә калдырып, охшашларын кушыгыз.

2. Авторны табыгыз.

3. Сәгыйть нинди малай? Сыйфатларын санап чыгыгыз. Аның үрнәк алырлык сыйфаты бармы?

4. Сәгыйть укый торган мәктәптә балаларны тыныш билгеләре дә тәрбияли. Өндәү, нокта, өтерләр сезнең мәктәптә дә балаларны яратамы, әллә яратмыймы? Яратмасалар, нигә яратмыйлар?

Җиңү

Безнең көннәрдә булган бу,
Түгел борын заманда;
Әллә кайларда да түгел,—
Үзебезнең Казанда.
Казандагы бер өйдә,
Көннәрнең, ди, берендә,
Тузаннар тузынганнар,
Тузаннар узынганнар.
Гөлләрне каплаганнар,
Көзгене таплаганнар,
Диван астына кергәннәр,

Шкаф башына менгәннәр,
Үзләрен бик гайрәтле,
Җиңелмәс дип белгәннәр.
Шактый шулай булмәдә
Хуҗа булып йөргәннәр.
Аннан килгән бер егет,
Исеме — Сәйдәш кебек.
Чүпрәк тотып кулына,
Чыккан, Алып батыр күк,
Тузаннарның юлына.
Чүпрәкне тыккан суга,
Могҗиза булган шунда...
Тузаннар өреккәннәр,
Идәнгә береккәннәр.
Тапканнар, ди, бер ышык,
Калмакчылар икән, ди,
Шушы ышыкка посып.
Сәйдәш атлы бу егет,
Сизеп алгач уйларын,
Барып җиткән почмакка,
Сузып-сузып кулларын.
Бөтен идән чыланган,
Ялтырап күлеп калган.
Тузан беткәч, гөлләр дә
Иркенләп сулыш алган.

Явыз тузан гаскәре
Тәмам көлкегә калган.
Елый-елый тузаннар
Суга төшеп чумганнар.
Шунда батып үлгәннәр.—
Шулай диләр күргәннәр.
Усал тузан яуларын
Ярты сәгать эчендә
Бу батыр кырып салган.
Үзе дә зыян алган:

Күлмәкләре чыланган,
Битләре дә пычранган,
Юешләнгән җиң очы.
Әмма горур басып тора
Биш яшьлек бу җиңүче.

Йолдыз Шәрәпова

?! **1.** Катнашучылар өчәү. Икесен тиз табасыз. Ә өченчесе шигырь юлларында посып утыра. Шул урынны күрсәтегез.

2. Ә ул өченче катнашучы ни ди? Тузаннан үрнәк алыгыз, диме? Гыйбрәт алыгыз, диме? Сәйдәш кебек батыр булыгыз, диме? Ни ди?

Шигырь вакыйгасын үзебезчә үзгәртик. Болай уйлыйк: Тузан кеше кебек тузына, узына, кача. Шулай булгач, Тузанның дошманнары да аның белән кеше кебек сугыша алалар. Ә Тузанның дошманнары кем? Әлбәттә, Чүпрәк белән Су. Аларга ярдәмгә Сабын да килә ала.

Вакыйганы болай башлыйк:

Тузанның тәртипсезлеген күреп торган Чүпрәк, краннан тамып торган Суга:

— Бу Тузанны тыймасак, өйдә тәртип булмас. Әйдә, барыбыз бергәләп акылга утыртыйк әле шуны,— ди...



Карандаш белән Бетергеч

Карандаш белән Бетергеч дуслашканнар. Бергә уйнаганнар, бергәләп дәрес әзерләгәннәр. Карандаш каты бәгырьле икән, ләкин аның каравы Бетергеч йомшак күңелле булган. Карандаш тузга язмаганны яза башласа, Бетергеч аларны берәү дә сизмәслек итеп бетерә барган. Тагын ялгыш язса, тагын бетергән. Матуррак, дөресрәк итеп язганчы шулай ярдәм итеп торган. Карандаш дустына рәхмәтләр әйтеп туя алмаган. Шулхәтле ярдәм итүчегә кем рәхмәт укымасын! Дуслар бер тапкыр да үпкәләшмәгәннәр, ел буена тату яшәгәннәр.

Танышлары дусларның тату яшәвенә көнләшкәннәр. Каләм исемле бер танышы Карандашны:

— Бетергеч белән дуслашып ялгыштың. Ул бит синең һәр сүзеңне юкка чыгарып бара. Шулай бетерә-бетерә ул сине тәмам хур итеп бетерәчәк,— дип котырткан.

Ә Бетергечне иске танышы Пәке үчекләгән:

— Ашыгып дуслаштың ул Карандаш белән. Яза-яза акылдан яздырачак әле ул сине, — дигән.

Иске танышлар максатларына ирешкәннәр. Дуслык җимерелгән. Карандаш, горурлыгымны саклыйм дип, җыен тузга язмаганны яза башлаган. Ә үпкәләгән Бетергеч аны бетерми, төзәтми икән.

Каләм белән Пәке дусларның шулай тиз арада аерылганын күреп борчылганнар. «Нигә болай булып чыкты соң әле бу? Югыйсә алдан кисәтеп тә куйган идек ләбаса»,— дип аптырашканнар.

Альберт Гатуф



?! Катнашучыларны әйтегез. Алар кемнәр? Араларында кешеләр бармы? Дуслык бозылуга кем гаепле? Каләмме, Пәкеме, Карандаш үземе, әллә Бетергечме?



Тәнкыйтьлиләр

Җеп Инәне болай тәнкыйтьли:

Миннән башка ул берни дә
Эшли алмый.
Минем белән тегә,
Минем белән ямый.

Инә Җепне болай тәнкыйтьли:

Беләсезме, сансызлыкка
Җитте тәмам өйрәнеп.
Кая барсам, нишләсәм дә,
Йөри миңа ияреп.

Нәҗип Мадьяров

?! Бәхәстә кайсысы хаклы: Инәме, Җепме?

Табышмаклар

«Алма» дисәң дә алалар,
Нәрсә соң ул, балалар?

(Алма)

Без безгә «без» дибез,
Сез безгә ни дисез?

(«Сез»)

Урманда бар, кырда юк,
Мунчада бар, өйдә юк.

(«М» хәрефе)

Сыерда бар, атта юк
Сарыкта бар, ...

(«С» хәрефе)

(Дәвам итегез.)

?! **1.** Без белгән катнашучыларга тагын нәрсә кушылды?

Табышмакларда катнашучы сүзләрне табыгыз. Мәсәлән, «кара» дип кешегә дәшсәң, әйләнеп карый. Ләкин «кара» дигән сүзгә «кара» дип дәшсәң карый алмый. Чөнки ул нибары сүз генә.

2. «Без» сүзенең ике мәгънәсен табыгыз.

Әсәрләрдә сүз дә, хәтта аларның аваз-
лары да сүздән сикереп төшәләр дә
әсәрдә **катнашучы** булалар.

Салкын аваз

«Р» авазы
Булган айлар
Салкын алар.
Берәм-берәм
Санап карыйк,
Бергә-бергә
Сынап карыйк.
Январь, январь —
Ява карлар...

?! «Р» авазы суыткан айларны үзегез әйтеп бетерегез.

«Р» авазы
Булмаса, җай:
Нинди җылы,
Мәсәлән, май!

?! «Р» авазы суыта алмаган башка айларны әйтегез.

Сынагансың
Син дә гел —
Салкын сулый
Сентябрь.

Шәүкәт Галиев

?! Сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь айларын кем суыткан? «Р» авазымы? Автормы? Күзен киткән кошлармы? Кем?

Үсми калган хәреф

Йөри, ди, «ң» каңгырып,
Йөри, ди, ул кайгырып.

Эшләре «ң»ның яман —
Үсеп җитми, ди, һаман

Сүз башында торырга
Һәм баш хәреф булырга!

Роберт Миңнуллин

?! Авторның елмаюын «ң» хәрефендә табыгыз. Ул хәреф кешегә ничек охшаган?

Әсәрдә теләсә нәрсә, хәтта сүзнең бер генә хәрефе дә катнашучы була ала икән. Автор аларның барысын да кешеләргә охшата. Әсәрдә катнашучы кешеләргә дә, кешегә охшаган предметларга да **персонажлар** диләр.

ӘЙБЕР СЫЙФАТЛАРЫ

Әйбернең теләсә нинди бер ягына әйбернең **сыйфаты** диләр.

?! Мәсәлән, таяк сыйфатлары: *ул — агач, яна, озын, шома, ботаксыз*... (Дәвам итегез.)

Өй, туп, каләм, эт, ай сыйфатларын мөмкин кадәр күбрәк итеп язарга тырышыгыз.

Күз

Күрәмсез, дусларым, күз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.

Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.

Чыгып баш калкыта сахрада уҗым,
Яшел хәтфә шикелле итә җем-җем...

Габдулла Тукай

?! Шигырьнең икенче яртысында автор көзнең башка сыйфатлары турында да яза. Үзегезне автор дип исәпләгез дә көзнең башка сыйфатларын табып языгыз.

Гали

Бер кешенең өч улы бар иде. Иң кечкенәләре Гали атлы. Аталары базардан өчесенә дә берәр алма алып кайтты. Алмалар бик пешкән — татлы, сулы җимешләр иде.

Берничә сәгатьтән соң аталары, балаларын янына чакырып:

—Алмаларны нишләттегез? — дип сорады.

Өлкән улы әйтте:

— Әти! Мин алманы ашадым. Эчендәге орлыкларны җыеп куйдым. Бакчабызга чәчеп алма агачы үстермәк буламын.

— Яхшы иткәнсең, улым! — диде атасы.

Уртанчы улы әйтте:

— Мин алманы ашадым. Бик тәмле, татлы җимеш икән. Әтиемә Хак Тәгалә исәнлек бирсен дип дога кылдым.

Атасы янә:

— Яхшы иткәнсең, улым! — диде.

Өченче улы Гали атасына карап әйтте:

— Алманың яртысын ашадым...

Атасы сорады:

— Яртысын нишләттең?

Гали куркып, кызарып әйтте:

— Күршебезнең улы Вәли авырып ята. Барып, яртысын аңа бирдем. Бик куанды, дога кылды.

— Бәрәкалла, улым! Син бигрәк тә яхшы иткәнсең! — дип, атасы Галинең битеннән, күзләреннән үпте.

Дәрдемәнд

?! **1.** Катнашучыларны әйтегез.

Аларга мондый бәя бирик: акыллы, берсеннән-берсе яхшырак уллары булган өчен әтиләре бәхетле кеше.

Беренче улы эш яратучы.

Икенче улы әдәпле.

Гали нинди малай?

2. Ни өчен хикәя «Гали» дип аталган?

Зәңгәр күл

Әкияттәге күлләр күк
Бар бик матур зәңгәр күл.
Әйтерсең лә күк шәүләсе
Төшеп зәңгәрләнгән күл.

Суы чиста: топ-тоньк,
Гөлгә кунган чык кебек.
Шундый тонык, күренә төбе...
Анда су да юк кебек.

Анда зәңгәр төннәрдә
Ай да төшеп тирбәлә.
Сайрап туймый таң алдыннан
Кошлар якын-тирәдә.

Ялт иттереп су өстен
Көндез кояш та, төшеп,
Матур итеп күзен кысып,
Күлдә ята су эчеп.

Урманда бар миләш тә,
Төрле-төрле җиләк тә.
Җиләкләре шундый тәмле! —
Тормыйм инде сөйләп тә.

Карлыганнар бар анда,
Бар бөрлегән, балан да.
Ул чәчәкләр, гөлләр дисәң —
Гөрләп үсә аланда.

Бари Рәхмәт

?! **1.** «Нәрсә турында?» соравын биреп катнашучыларны табыгыз. *Шигырь нәрсә турында? — Күл турында. Тагын нәрсә турында? ...* (Башкаларын үзегез табыгыз.)

2. Китабыгызны ябыгыз да күл сыйфатларын әйтегез. Күпмесен исегездә калдырдыгыз?

3. Урман сыйфатларын да шул рәвешле әйтегез.

4. Баштагы сигез юлны ятлагыз.

Чебиләр

Өй эчендә чебиләр
«Чип-чип-чип!» — дип йөриләр.

Кечкенә канатлары,
Муеннары сап-сары.

Күпереп тора йоннары.
Ул — аларның туннары.

Мин җим сипсәм бииләр:
«Акыллы бит син, Дилбәр.

Син сип, сип, сип күп!» — диләр.
Үзләре гел чүплиләр.

Алар курка этләрдән,
Тилгән-кош кебекләрдән.

Әни шуңа: «Дилбәрем,
Сакла,— ди,— чебиләрең».

Җәйләр менә үтәрләр,
Чебиләр дәү үсәрләр.

Шул вакыт инде минем
Әни биргән кәрзинем
Йомырка белән тулыр...
Тулырмы? Тулы-ы-ыр!

Мәхмүт Хөсәен

?! 1. Чебиләрнең сыйфатларын әйтегез.
2. Дилбәрнең сыйфатларын әйтегез.
3. Дилбәр кәрзинем тулыр ди. Ни өчен?

СҮЗ СЫЙФАТЛАРЫ

Башка кия торган бүрек бар. «Бүрек» дигән сүз бар. Ләкин бүрекне киеп була. «Бүрек» сүзен башка киеп булмый.

«Бүрек» сүзенең үз сыйфатлары бар. Ул биш хәрефле, биш авазлы. Ул сүз эчендә хәтта бүре дә бар. Ә башка кия торган бүректә бүре юк. Башка кия торган бүрек бүресез дә, «бүрек» дигән сүзсез дә яши ала.

Сүз кайвакыт бүреген ташлап китәргә дә сәләтле. Авторлар ихтыярына буйсынып, сүз генә булып та яшәп ала. Нигә яшәмәсен, аның да үз сыйфатлары бар бит.

Башка сүзләр дә, «бүрек» сүзеннән күрепмедер, иясен ташлап киткәлиләр.

«Сүз» дигән сүзнең үзендә өч аваз бар. Шуларның берсен башка авазга алыштырыйк. Мәсәлән, «с» авазы урынына «б» куйсак, «сүз» «бүз»гә әйләнә. Бүздән күлмәк тегеп була. Ә «бүз» сүзеннән күлъяулык та ясап булмый.

?! «Сүз»нең башка авазларын да шул рәвешле башка сүз килеп чыгарлык итеп алыштырыгыз.

Сүзләр бик күп, ә авазлар аз булганлыктан, сүзләр үзләренә кирәк авазларны башка сүзләрдән бурычка алып торалар. Шуңа күрә авазлары уртак булган сүзләр күп.

Бик күп сүзләр башка сүзләргә охшыйлар.

Сүзләрнең шундый охшашлыгыннан файдаланып, шагыйрьләр шигырь язалар. Ә сезнең кебек балалар, охшаш сүзләр табып, үртәвеч, такмаклар, хәтта шигырьләр дә иҗат итәләр.

Такмаклар, үртәвечләр

Борын-борын заманда Бибинур исемле бер кыз «чабата», «карга бата» һәм «кигән», «көтүдән» сүзләренең охшашлыгын күргән дә мондый җыр уйлап тапкан:

Аягымда кызыл яулык,
Башларымда чабата;
Җәйнең эссе көннәрендә
Аягым карга бата.

Иртән торып тышка чыксам,
Сыер чабата кигән;
Очып бара, очып кайта
Безнең кәҗә көтүдән.

Бибинур җырын иптәш кызы Бибисарага җырлаган. Бибисара рәхәтләнеп көлгән.

— Тузга язмаган вакыйгалар турындагы җыр бик кызык була икән! — дигән.

Җырны Гайниҗамал әби дә ишетеп тел шартлаткан.

— Адәм ышанмаслык нәрсә уйлап тапкансың, бигрәкләр дә кызык!— дигән.

Бибинур шуннан соң көн дә бер такмак чыгара башлаган. Бибисара көн дә эче катып көлгән. Менә ул җырлар:

Әнә килә бер машина,—
Бүрек кигән башына;
Кетәклеккә менгән идем,
Тавык типте башыма.

Иртән торып тышка чыксам,
Сыер сайрый абзарда;
Тавыкларга тоз ялаттым
Печән салдым казларга.

Иртән торып тышка чыксам,
Тараканнар кар көри;
Ә чебеннәр, итек киеп,
Көрәгән җирдә йөри.

Безнең песи бигрәк уңган,
Казанга су тутыра;
Бозавыбыз мич башында
Оек бәйләп утыра.

Биек тауның башларында
Сабан сөрә бер карга;
Агыйделдән су апкайттым
Бастырыклап бер арба.

?! Түбәндәге такмазаны дәфтәргә тутырып язызыз.

Бар иде, ди, бер Давыт,
Җикте, ди, сукыр тавык,
Төяде, ди, табак-савыт,
Салды, ди, ярма,
Җикте, ди, арба.
Барадыр иде, ди, чабып,
Әй китте, ди, ... !
Түгелде, ди, ярма,
Җыелды, ди, ... ,
Чүплиләр, ди бар да.

?! Үртәвечләргә исемнәр бирегез. Мәсәлән, беренче үртәвечне «Ялкау» дип була...

Ибрай, Ибрай,
Тавыкларга сип борай;
Әтәчләрең кычкыра,
Кәҗәләрең пошкыра.

Нәсип, Нәсип,
Тавыкларга ярма сип;
Анда сипмә, монда сип,
Такыр җирне карап сип!

Кәрами, Кәрами,
Казларын да карамый,
Кәҗәсен дә карамый —
Бер эшкә дә ярамый.

Ишми, Ишми,
Мич башыннан төшми;
Мич башыннан төшми,
Ничек тәне пешми.

Әй Хисамый, Хисамый,
Авызың сүздән бушамый;
Аз сөйләш тә күп эшлә —
Эшләмәгән — ашамый.

Балалар бик көлгәч, җырны олылар да җыелып тыңлаганнар.

— Уйлый беләсең, Бибинур,— дигәннәр алар.— Тагын шундый җырлар уйлап чыгар. Без тагын тыңларга килербез.

?! Такмакларны тыңлагач, балалар нигә көлгәннәр? Алар сезгә дә кызыкмы?

Кызык булса, ни өчен кызык? Кызык булмаса, ни өчен кызык түгел?

Бибинур дус кызын да шундый такмаклар чыгарырга өйрәтә башлаган.

Бибисара башта мондый үртәвеч уйлап тапкан:

Барып кердем Хәйдәргә,
Башын тыккан әйрәнгә.
Башын алгач әйрәннән,
Куркып киттем Хәйдәрдән.

Бибисара үртәвечләрне бик күп уйлап чыгарырга теләгән. Ләкин иң кирәкле сүзләрен таба алмаган:

Барган идем Якубка,
Башын тыккан...

Барып кердем Ногманга,
Башын тыккан...

Барып кердем Гатага...

Барып кердем Хаматка...

?! Бибисара нинди сүзләр таба алмаган? Табыгыз.

Бибисараның үртәвечләрен Гайниҗамал әби бер дә ошатмаган. Ул, кызга карап, тамак кырган. (Ул заманда тамак кыру «кеше үртәү акыллы бала эше түгел» дигәнне аңлаткан.)

Әбинең тамак кыруына Бибисара үпкәләгән. Ул, дустының уңышы өчен шатланасы урынга, аңардан көнләшә башлаган һәм менә мондый такмак уйлап чыгарган:

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр кыярлар.
Бик күтәрмә борыныңны,
Чиләк асып куярлар.

Такмакны Бибинурга җырлап биргән дә үзе егыла-егыла көлгән. Ләкин Бибинур көлмәгән. Ачуланмаган да.

Такмакны Гайниҗамал әби дә ишеткән икән. Ул да көлмәгән. Бибинурга:

— Вак-төяк бәйләнүләргә җавап бирми, дәшми калу — акыллы кеше эше ул, кызым. Әһем-әһем,— дип китеп барган. (Ул заманда «әһем-әһем» дип әйтү «син безнең авылда иң акыллы кыз» дигән сүз булган.)

?! **1.** Кызлар чыгарган такмаклар сезгә ошыймы? Ошамыймы? Ни өчен?

2. Мыскыллаучыга каршы дәшми калуны әби ни өчен акыллылык дип бәяләгән?

Бибинурга охшатып, башка балалар да менә мондый такмаклар чыгара башлаганнар:

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр күмерләр.
«Ике»ләрсез бигрәк рәхәт
Узар иде гомерләр.

Әнә килә автомобиль,
Аны йөртә Гөлҗамал.
«Биш»ле алулар күңелле,
«Ике»ле алсаң бик яман.

?! **1.** Нокталар урынына «мактанчык», «сөйләшә» сүзләренә охшаган теләсә нинди башка сүзләр эзләп табыгыз.

2. Такмакларны дәфтәрегезгә тутырып языгыз.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр ак ... .
Хәерниса яхшы укый,
Бераз гына мактанчык.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр ... .
Мактанасы килгән өчен
Бик кычкырып сөйләшә.

Авазлары уртак булган сүзләр янәшә килсә, аларга **рифма** диләр.

Сүз эчендә сүз

Сүзнең тагын бер бик матур сыйфаты белән танышыйк. Ул үзе әллә ничә сүзгә аерыла ала икән. «Китап» сүзе эченә керсәң, *кит* балыгы белән очрашасың. «Күлмәк» эченә керсәң, *мәк* чәчәген күрәсең. Бик матур *күл* дә күрәсең...

?! **1.** Кайбер сүз эченә үзегез кереп карагыз әле, анданиләр таба алырсыз икән? Менә ул сүзләр: *сарык, агач, бакча, надан, юаш, таш, барабыз, сыерчык, тәртипле, йозак.*

2. Сүзне һәм аның эчендәге сүзләрне кертеп, җөмлә төзегез. Мәсәлән:

Аның аКЫЛы КЫЛны кырыкка ярырлык.
Мин күргән сАРЫК бик АРЫК иде. ...

Шагыйрьләр, сүзнең шул сыйфатыннан файдаланып, берсеннән-берсе матур шигырьләр иҗат иткәннәр.

Чагу

Бигрәк куркыныч
Ул елан чАГУ —
Күренеп тора
Эчендә АГУ.

Таяк

Бабай тикмәгә
Таянмый тАЯК.
Таяк эчендә
Бар икән АЯК.

Шәукәт Галиев

?! Аңлатып карагыз әле: автор ничек шаярта?

Карлы-карсыз карбыз

Карбыз буламы КАРсыз?
Юк, КАРбыз булмый ансыз.
Ул КАРлы да булалмый,
Булмый ул КАРбыз андый.
КАРбызларның КАРсызын
Я булмаса, КАРлысын
Күргәнегез бармы соң?

Роберт Миңнуллин

?! Катнашучыларны эзләп табыгыз. Шуларның берсе — сүз. Нинди сүз?

Ачык авыз

Күр,
Ак куян —
Куркак куян.
Ята йоклап,
Куәт туплап.
... ,
Куян,
Уйлан, куян —
Сиңа Кыям
Капкын
Куйган!
Капкын — усал,
Капкын — явыз.
Каба күрмә,
Ачык авыз!

Роберт Миңнуллин

?! Сүзләрнең без өйрәнә торган сыйфатын искә төшерегез дә шигырьдә без юри төшереп калдырган сүзне табыгыз.

Алма

Алмасы да алмасы —
Өзеп кенә аласы!
Өзмим әле — баллансын,
Бераз гына аллансын!

Роберт Миңнуллин

?! **1.** Үзегез сорау куеп, үзегез җавап бирегез.

2. Соңгы юлдагы «аллансын» сүзендә тагын берничә сүз бар. Шуларны табыгыз. Тапсагыз, Роберт абыегыз Миңнуллин шигыренә бергәләп тагын бер юл өсти алабыз:

Монысын алма, ...

Дәвам итегез: ни өчен автор алманы алмаска куша?

Айлы малай, айлы бабай

МалАЙда да бар АЙ,
БабАЙда да бар АЙ.
Ничек инде алАЙ?
ШулАЙ инде, шулАЙ!

Роберт Миңнуллин

Эчендә ае булган тагын нинди сүзләр беләсез? Шуларны файдаланып, шигырьне дәвам итеп карагыз.

КҮРЕНЕШ СЫЙФАТЛАРЫ

Без күккә карыйбыз да ай күрәбез.

Берзаман күктә йолдызлар калка. Без айны да, йолдызларны да күрәбез. «Күктә йолдызлар күп. Ай да бар»,— дибез.

Янәшә торучы күп әйберләргә **күренеш** диләр.

Тугайга чыклар төшкән

Болында — тугайларым,
Тугайда — томаннарым.
Барысы-барысы минеке —
Тугайдагы малларым.

Тугайга чыклар төшкән,
Чыкларны кошлар эчкән.
Көтүчене дә берәрсе
Көтәдер әле кичтән.

Урманда — аланнарым,
Аланнарда— малларым.
Барысы-барысы минеке —
Шул бәхетле таңнарым.

Сибгат Хәким

Катнашучыларны барлыйк. Шигырьдә болын бар. Болында тугай. Тугай өстендә томан, чык. Чык эчүче кошлар. Томанлы тугайда көтү бар. Ә көтү янында көтүче басып тора. Әнә никадәр катнашучы. Алар барысы да берберсенә якын торалар.

«Шигырь ни турында?» дигән сорауга: «Авылның матур бер күренеше һәм авторның шул күренешкә карап соклануы турында», — дибез. Шигырь ике өлешкә бүленде.

Шигырьдәге күренешне үзегез рәсем итеп ясагыз. Авторны катнаштырырга да онытмагыз.

Дим буенда

Кояшның җылы нурлары астында ялтырый-ялтырый Дим ага.

Әнә аның кырыенда чиксез киң болынлык, аннан ерак та түгел — таллык.

Якты суның өстендә аккошлар йөзеп йөри. Болынлыкта төрле кошлар сайрый. Ара-тирә акчарлакларның ачы тавыш белән кычкырганнары ишетелеп китә.

Монда һәрнәрсәдән иркенлек, бәхет аңкый. «Мондый матурлык, мондый байлык эчендә адәмнең бәхетсез булуы мөмкин түгелдер» дигән уй килә.

Әнә тагын еракта Дим буена утырган зур гына авыл. Аның бер читендә урман шикелле куе бер бакчалык күренә. Бакча бик күптән утыртылган булса кирәк: андагы агачлар инде тәмам картайганнар. Аңа инде күптәннән бирле адәм кулы орынмаганын белергә була. Агачлар арасыннан зур гына агач өйнең ташландык хәрабәсе күренә. Тәрәзәләре такта белән томаланган. Баскычлар янтайган, морҗаларга чәүкәләр, тәрәзә башларына күгәрченнәр оялаганнар.



Ишегалдына, йөрүче булмаганга, ямь-яшел чирәм үскән. Бөтен җир буш...

Картларның сүзе буенча, элек бу хәрабә мирза гаиләсенең кайнап торган оясы булган...

Төннәрдә монда бигрәк тә тын була, тик аратирә шомлы кош — мәче башлы ябалакның ачы тавыш белән кычкырганы гына ишетелә.

Әбиләр кышкы озын төннәрдә, орчыкларын эрли-эрли, балаларга ул хәрабә турында әллә нинди куркынычлы әкиятләр сөйлиләр. Картлар исә бакчага бер карап алалар да мәгънәле генә итеп: «Бичара мирзаның балаларына бу нигездә рәхәт күрергә язмаган икән инде!..» — диләр. Тагы шуның артыннан ук: «Мал да бар иде... дәүләт тә... Булмаса булмый икән инде!..» — диләр. Шундый бер гаиләнең болай эзсез-нисез юк булуына алар күп вакыт аптырыйлар.

Садри Җәләл

?! **1.** Текстны ике кат укып чыгыгыз. Хәтердә калдыру өчен, «башта менә бу күренеш турында, аннан соң бусы турында сөйлим» дип, язманы ике өлешкә бүлегез.

2. *Дим елгасы, киң болынлык, таллык, аккошлар, акчарлаклар...* дип, күренешне таркатыгыз.

3. Беренче өлешне тагын бер тапкыр укыгыз. Аңа бер-ике генә сүзле исем бирегез.

4. Әсәрнең икенче өлешен кабат укып чыгыгыз. Икенче өлештәге күренешне *авыл, бакча...* дип, күз алдына китереп сөйләгез.

Туган җир

Туган җир, ахры, күңелемнән
Кайчан да китмәс.
Ул хакта җырлап, сөйләп тә
Сүзләрем бетмәс.

Кул изи үрләр, тауларның
Зәңгәр сыртлары.
Көтә капкасын киң ачып
Авыл йортлары.

Утыра кырыйда ялгыз
Җил тегермәне.
Күренә инде авылга
Көтү кергәне.

Ишетелеп куя таныш җыр,
Дәрт белән тулган.
Кибәннәр өстенә шәфәкъ*
Нурлары кунган.

Син ул — барасы юлыма
Яктылык сипкән.
Өзелмәс җепләрем сиңа
Бәйләнгән күптән.

Сибгат Хәким

?! **1.** Авыл күренешен кыска итеп сөйләгез.

2. «Бу шигырь ни турында? Тагын ни турында?» дип сорау бирегез дә әсәрне икегә бүлегез.

3. Авторны табыгыз. Ул ни эшли? Шигырьне игътибар белән тагын бер кабат укып чыксагыз, сорауга җавап бирү җиңелрәк булыр.

---

* *шәфәкъ* — кояш баеганда күктәге кызыллык

ХӘРӘКӘТ СЫЙФАТЛАРЫ

Болытлар агыла, яңгыр ява, җил исә, капка ачыла да, ябыла да... Барысы да хәрәкәтләнә, нидер эшлиләр.

Сез мәктәпкә барасыз. Кайтасыз. Өйдә олыларга ярдәм итәсез. Кушканны көтеп торсагыз, тик торып идегез, шуңа күрә үз теләгегез белән идәнне себереп чыгарасыз. Дымлы чүпрәк белән тузаннарны сөртәсез. Уйныйсы килсә дә уйнарга чыкмыйсыз: «Бәрәңге әрчү — файдалы хәрәкәт, уен качмас», — дип, бәрәңге әрчисез. Ә ашап-эчкәннән соң табак-савыт юу — сезнең өчен чүп тә түгел, күнегелгән гамәл инде ул.

Үзегез турында язылганны укыгач: «Мин шундый»,— дип эчтән генә шатландыгызмы? «Ялган бу, мин андый түгел»,— дип, авторны гаепләдегезме? Әллә борчылдыгызмы?

Үзегезгә үзегез эчтән генә бәя бирегез.

Үзеңне мактатырга теләп кылану да — хәрәкәт. Ләкин хур итә торган хәрәкәт. Үзеңнең кимчелегеңне күрү — менә монысы ичмасам хәрәкәт! Кешене акыллы итә торган матур хәрәкәт.

Җир йокысы

Кырга ак кардан
Юрган ябылган;
Җир язга чаклы
Уйкуга* талган.

Ул тормас, йоклар,
Кышлар үтмичә,—
Кыйбладан кошлар
Кайтып җитмичә.

Язның айлары,
Апрель, майлары,
Бик матур сызлып
Аткан таңнары;

Урман шаулавы,
Кошлар сайравы,
Күкләр күкрәве,
Яңгыр аннары.

---

* *уйкуга* — йокыга

Койну көн саен
Кояш нурында;
Аннан соң тагын
Төшкән чык төндә.

Бу хәлләр җиргә
Барчасы бергә
Калган тик инде
Төштә күрергә.

Җир йоклый тыныч,
Күреп тәмле төш.
Уяныр әле,
Тукта, үтсен кыш!

Габдулла Тукай

?! **1.** Шигырьдә өч заман бар. Җирнең йоклавы — хәзерге заман.

Яз айлары, кошлар сайравы кайсы заман? Киләчәк заман турында кайда әйтелә?

2. Катнашучыларны әйтегез. Җир белән кыш — катнашучы. Кар да катнашучымы?

3. Автор Габдулла Тукай «мин монда» дип әйтеп тора. Кайда әйтә?

Эш

Оста иртән үк
Эшкә керeште,
Эш кораллары
Юксынган эшне.

Сөенде ышкы:
— Эш-эш, эш-эш! — дип.

Шатланды пычкы:
— Тыр-рыш, тыр-рыш! — дип.

Очынды чүкеч:
— Шәп! Шәп! Шап! Шап! — дип.

Талпынды балта:
— Шат! Шат! Шалт! Шалт! — дип.

Куллар, мускуллар
Сагынган эшне.
Кинәнеп эшли —
Бәхетле кеше.

Шәүкәт Галиев

?! **1.** Эш коралларының төрле хәрәкәтен бер сүз белән әйтеп була. Шул сүзне уйлап табыгыз.

2. Соңгы ике юлны үзгәртеп, башкача языгыз. Шуннан соң «Нәрсә ул бәхет?» дигән сорауга автор җавабын таба аласыз.

3. Ышкы, пычкы, чүкеч, балта — барысы да хәрәкәттә. Хәрәкәтләре төрле-төрле. Алар ничек хәрәкәтләнә?

4. Бөтен нәрсә эшләргә, хәрәкәтләнергә ярата. Ни өчен шулай?

«Эш» шигыре белән танышкач, ни өчен икәнен аңладыгызмы?

Файда китерә торган хәрәкәткә **эш** диләр. Хәрәкәтнең файдасызы да була.

Шәүкәт абыегыз Галиевнең тагын бер шигыре белән танышыйк.

Чабалар

Исхак та чаба,
Мисбах та чаба.
Берсен зурлыйлар,
Берсен хурлыйлар.

Исхакта чалгы —
Болында чаба.
....
....

Исхак белән Мисбах икесе дә хәрәкәтләнәләр. Исхакның хәрәкәте — эш. Мисбах хәрәкәте нинди? Ул ни эшли? Соңгы ике юлдагы нокталар урынында автор шул сорауга җавап бирә. Сез дә автор булыгыз. Үзегез тапкан җавапны, ике юл итеп, дәфтәрегезгә языгыз.

Алма, пеш!

Әшти һәм Мөшти исемле ике ялкау булган. Беркөнне болар бакчага кереп алмагач астына чалкан ятканнар. Алмалар өстән аларның авызларына карап тора... Бик ашыйсылары килсә дә, торып алырга ирененәләр икән. Әшти түзә алмаган:

— Алма, пеш, авызыма төш! — дип, авызын алма сыярлык итеп ачкан.



— Ничек иренмичә әйтәсең аны! — дип, Мөшти яны белән әйләнеп яткан, ди.

Мәзәкне болай кыскартып сөйлик: Әшти ялкау. Мөшти Әштидән дә ялкаурак.

Башкача кыскартыйк: ике ялкау эшләмичә генә ашарга телиләр. Тәмамланмаган хәрәкәт

килеп чыкты. Әйдәгез, хәрәкәтне дәвам итеп язып бетерик. Без дә мәзәкнең авторы булыйк.

Инде хәрәкәтнең тагын бер сыйфаты белән танышыйк. Шәүкәт Галиев шигырьләренең икесендә дә эш тәмамланмаган. Балта остасы йортын төзеп бетергәч, ә Исхак печәнен чабып бетергәч кенә эшләрен тәмамлыйлар.

Тәмамланмаган хәрәкәткә **эпизод** диләр.

Буран

Урамда буран,
Мин өйдә торам.
Тәрәзә аша
Тик авыз ерам...
Әй җил выжылдый,
Буран дуылдый.
Ачулы песи
Кебек чыелдый...
Җиңде, ди, бугай,
Дуланып шулай.
Әй бичаракай,
Шаярма алай!
Мичләр ягылган,
Өйләр җылынган.
Тиздән яз килер,
Кирәгең бирер!

Гомәр Толымбай

?! Шигырьдәге тәмамланмаган хәрәкәтләрне (эпизодларны) табыгыз.

Ни өчен тәмамланмаган? Аңлатыгыз.

?! «Бу эзләр хәрәкәтме, хәрәкәт түгелме?» — дип уйлый чаңгычы кыз. Уйларга яратучы шул кызга ярдәм итегез. Чаңгы эзе хәрәкәтме?

Китап һәм балалар

Дүрт-биш бала җыелганнар бер урынга
Нәкъ уртада берсе китап тоткан кулга.
Һәммәсе дә колакларын торгызганнар:
Берсе укый, башкалары тыңлый шунда.
Утыралар китап укып, күңел ачып,
Шатлыкларын бергә-бергә уртаклашып.
Кайвакытта тыңлый болар тып-тын гына,
Кайчагында көлешәләр шаркылдашып.

Мәҗит Гафури

?! Ике иң мөһим эпизодны табыгыз.
Балалар ни өчен шатланалар?
Ни өчен кайчак тып-тын утыралар?
Ни өчен кайчак көлешәләр?

Вакыйга тәмамланмаган: балалар җыелганнар, укыйлар, шатланалар... Вакыйга тәмамлансын өчен, алар тагын ни эшләргә тиеш?

Шөпшәләр

Торалар урманда —
Дачада балалар.
Көн саен аланга
Уйнарга баралар.

Бар шунда бик юан,
Картайган бер юкә.
Шул юкә яныннан
Бик матур юл үтә.



Юкәдә — куышта
Шөпшәләр яшиләр.
Бу тырыш бөҗәкләр
Көн буе эшлиләр.

Сокланып карыйлар
Шөпшәләр аларга.
Уйламый берсе дә
Боларны чагарга.

Аланда уйнарга
Көн саен балалар
Бик тыныч, тәртипле
Тезелеп баралар.

Беркөнне Илгизәр
Бик артык узынды.
Барды да шөпшәнең
Оясын туздырды.

Шул көннән соң инде
Шөпшәләр котырды —
Үткән бер кешене
Чагарга тотынды.

Гасыйм Лотфи

?! Шигырьне үз сүзләребез белән сөйләсәк, менә болайрак булыр иде:

1) Тәртипле балалар арасында бер тәртипсез малай бар. Ул яманлык эшли — шөпшә оясын туздыра. (Илгизәр хәрәкәте әлегә эпизод кына. Хәрәкәт дәвам итә.)

2) Илгизәр яман эше өчен җәзасын ала. Ләкин аның бер яман эше аркасында күп кешеләргә зыян килә.

Хәзер әсәрне икегә бүлү җиңел. Аны «Тәртипсез малай турында» һәм «Җәза бирүче шөпшәләр турында» дип бүләбез.

Хәрәкәт яман эшкә җәза булып туктады.

Тәмамланган хәрәкәткә **вакыйга** диләр.

Рәсемгә шигырь вакыйгасының беренче эпизоды төшерелгән. Шигырьдә вакыйга тәмамлана. Рәсемнең икенчесен ясап, сез дә вакыйганы тәмамлагыз.

Чүкеч

Бакый кадак кагарга ярата. Кулына чүкеч-кадак эләктеме, коймага да кага, өй стенасына да, сарай почмагына да кага.

Тик шунысы яман: кадак урынына чүкеч еш кына малайның үз бармагына китереп суга. Үзәге өзелеп авыртса да еламый Бакый, тешен кысып түзә.

— Тырнагың тагын кара көеп чыккан бит, малай актыгы, — дип битәрли әтисе. — Тотынма дип ничә әйттем. Кадак җене кагылган, ахрысы, сиңа.

— Мин түгел, чүкеч... — дип акланмакчы Бакый, — чүкеч әшәке минем. Синеке әллә ничек, туры суга. Миңа да шундые кирәк.

— Ә-ә, юкәдә икән чикләвек! — ди әтисе. — Алайса, әнә сиңа такта башлары, менә бу тартмада кадак. Шуны кагып бетерсәң, кулга сукмый торган әйбәт чүкеч алып кайтып бирермен.

Һәй рәхәтләнде Бакый. Иртән дә кага, көндез дә кага, ашыйсы килсә, аяк өсте генә капкалап чыга да янәдән шакы-шокы, шакы-шокы, шакы-шокы...

Кырыкмаса кырык тапкыр кулына сукты, хәтта тырнак төбеннән кан бәреп чыкты.

Ул кадәресенә түзмәс тә иде әллә, тик яңа чүкеч кызыктыра аны. Әтисенеке кебек, кадак башына туп-туры суга торган чүкеч кызыктыра.

Тырыша торгач, тартмадагы кадак шактый кимеде. Кадак бетә барган саен, чүкеч кулга сирәгрәк суга башлады.

* * *

Әтисе, килеп, аның эшен тикшерде.

— Йә, ничек, беттеме? Булган бу, минемчә. Әйдә, яңа чүкеч алырга кибеткә барабыз. Барышлый бусын чүплеккә ташлап китәрбез.

Бакый чүкечне бер алды, бер куйды, әйләндереп-әйләндереп карады, кизәнеп-кизәнеп кадак башына сукты. Әйбәт суга иде чүкеч. Искиткеч әйбәт суга иде. Ул хәзер Бакыйга бик кадерле, бик кызганыч тоелды.

— Юк, әти, ташламыйк без аны,— диде малай.

Әтисе мыек астыннан гына көлеп куйды:

— Нишләп тагын? Үзең яңаны сораган идең.

— Бусы... бу чүкеч өйрәнеп җитте бит инде,— диде Бакый.— Кулга сукмый, кадакны кәкрәйтми. Миңа башкасы кирәк түгел.

— Шулай дисеңме? Алайса, син хәзер келәшчәне өйрәт инде. Кадакны юкка әрәм итәргә ярамый, кеше хезмәте ич ул. Келәшчәне өйрәтеп җиткергәч, пычкыны өйрәтә башларсың.

— Аннары балтаны! — дип дәртләнеп китте Бакый.

— Әйе, балтаны, аннары өтергене. Бераз үскәч, тракторны иген игәргә өйрәтерсең.

— Әти! Әти! Аннары комбайнны. Аннары машиналарны...

— Аннан соң самолётларны,— диде әтисе, зәңгәр күккә карап.

Габделхәй Сабитов

?! **1.** Хикәянең баштагы өлешенә «Теләк» дип тә, «Начар чүкеч» дип тә исем бирә алабыз.

Икенче өлешенә исем эзләгез.

2. Хикәядәге вакыйганы сөйләгез.

3. Хикәясе белән автор безгә ни әйтә? Шуннан соң без үзебезгә нинди нәтиҗә ясыйбыз?

Бакый суккан саен кадагын кәкрәйтә. Ник кәкрәйтә? Әлбәттә, суга белмәгәнгә. Ләкин чүкечне гаепли. Автор Бакыйдан көләме? Дөрес җавап тапсагыз, автор нәтиҗәсен беләсез.

?! Рәсемнәрдәге ике эпизодны кушып сөйләгез.

Хәрәкәтне тәмамлау өчен, тагын бер эпизод кирәк. Анысын үзегез уйлап табыгыз һәм өченче рәсемне ясагыз.

Яхшылыкка — яхшылык

Күптән, бик күптән бер бабай белән бер әби яшәгән. Икесе дә миһербанлы*, яхшы күңелле кешеләр булганнар.

Кышның салкын бер кичендә бабай урманга утынга киткән.

Утынын турап бәйләгән. Җилкәсенә салган. Таудан төшкәндә, кинәт туктап калган. Бик кызганыч тавыш белән кемдер ярдәмгә чакыра икән. Тавыш ишетелгән якка килсә, ни күзе белән күрсен — капкынга торна эләккән. Канатларын җилпи, ыңгыраша...

— И-һи-һи, мескенкәй. Бәхетсезлеккә юлыккансың икән бит,— дигән бабай һәм торнаның аякларын капкыннан ычкындырган. Тозактан котылгач, торна очып киткән. Үзе оча, үзе шатлана-шатлана нидер каңгылдый, ди.

Бабай өенә кайткан. Әби белән чәй эчәргә утырганнар. Шулчак кемдер ишек каккан.

— Төн уртасында кем йөри? — дип бабай ишеген ачып җибәрсә, каршысында ап-ак карга күмелгән бик матур бер кыз басып тора икән.

---

* *миһербанлы* — шәфкатьле

— Буранда адаштым. Юлны кар баскан,— дигән кыз.

— Кер, кызым, кер, кунак яратабыз без,— дип чакырган әби.

— Бик салкын, туңгансыңдыр. Кер, әйдә, мич каршысына утыр, җылын, — дип, әбинең сүзләрен куәтләгән бабай.

Кыз өйгә кергән, мич каршысына утырган.

— Исемең ничек, кызым? — дип сораган әби.

— Минем исемем Коштай, әби.

— Исемең матур икән, Коштай,— дигән әби.

Ягымлы кыз әби белән бабайга ошаган. Икенче көнне китәргә җыенгач, алар кызны үзләрендә калырга кыстаганнар:

— Балабыз юк. Ялгыз яшибез. Бездә калмассыңмы, кызым? — дип ялынганнар.

Кыз да ятим бала икән. Монда калырга бик шатланып риза булган.

— Яхшылыгыгыз өчен үзегезгә матур келәм тукып бирермен. Тик бер генә шартым бар: мин келәм тукыганда, бүлмәгә кермәсәгез иде,— дигән.

* * *

Кунак кыз шул көнне үк, бүлмәсенә кереп, келәм тукый башлаган. Өч көн эшләгәннән соң, әби белән бабайга төрелгән тукыма чыгарып биргән.

— Минем мондый матур келәмне гомеремдә дә күргәнем юк! — дип шатланган әби.

Бабай кызга карап алган да, борчылып:

— Бик йончыган кебек күренәсең, кызым,— дигән.

Ул арада келәмнәр сатып алучы килеп кергән. Әби кулындагы гүзәл келәмне күргәч, аның күзе дүрт булган.

— Ай-һай кызыгыз оста икән! — дигән. Әбигә берничә алтын тәңкә биргән. Алтын тәңкәләр кояш кебек ялтырый, тимердән дә авыр икән. Әби белән бабайның мондый байлыкны үз гомерләрендә күргәннәре булмаган. Алар кызга рәхмәт әйтеп туя алмаганнар:

— Бик зур рәхмәт сиңа, кызым Коштай. Мондый акчалар белән тормыш җиңеләя хәзер,— дигәннәр.

* * *

Яз җиткән. Карлар эрегән. Кояш җылыта башлаган. Коштай авыл балалары белән дуслашып өлгергән. Алар бергәләп уйнаганнар, көлгәннәр. Ләкин беркөнне келәмнәр сатып алучы тагын килеп чыккан. Ул бу юлы да Коштай тукыган келәмне сораган.

— Сорама да, кызыбыз келәм тукып бик арый,— дигән бабай. Ләкин теге аның учына алтын тәңкәләрне көчләп салган.

— Тагын да күбрәк бирермен. Бу юлы сатмасагыз, бүтән берне дә алмыйм, — дип куркыткан.

— Башка зур хәсрәт килде. Инде ни эшләр-

без? — дип хафаланган әби белән бабай. Алар сөйләшкәнне Коштай тыңлап торган икән.

— Борчылмагыз. Тагын берне тукып бирермен! Тик бу соңгысы булыр. Үтенеп сорыйм, зинһар өчен, мин эшләгәндә, бүлмәгә керә күрмәгез, — дип, тагын бер мәртәбә кисәткән.

Коштай бүлмә ишеген япкан да икенче келәмен тукырга керешкән. Туку машинасы көн эшләгән, төн эшләгән. Өч көн үткәч, теге кеше тагын кергән.

— Йә, миңа дигән келәм өлгердеме? Күрсәтегез! Кая ул?

Әби белән бабай сискәнеп киткәннәр.

— Күрсәтергә ярамый! Бүлмәсенә кермәскә кушты Коштай! — дигәннәр.

— Харап икән. Коштай кушкан икән! — дигән теге кеше һәм бүлмә ишеген ачып җибәргән. Ә эчкә карагач, хәйран калган:

— Анда торна утыра. Торна, тор-рна! — дип кычкырып җибәргән.

Чыннан да, туку машинасы янында торна утырган була. Торна, канатларын җәеп, борыны белән канат астындагы йомшак каурый-мамыкларын йолкып, шул каурый-йоннардан келәм тукый икән.

* * *

Икенче көнне әби белән бабай әлеге бүлмәне ачып карасалар, бүлмә тып-тын, беркем дә юк. Туку станогында күз явын алырдай келәм ята. Тирә-юньгә торна мамыгы чәчелгән...

Кичкә таба урамда балалар:

— Әби, бабай, чыгыгыз тизрәк, монда килегез! — дип кычкырганнар.

Әби белән бабай чыгып күккә карасалар — торна! Бабай коткарган торна! Каңгылдый, өй өстендә әйләнеп оча. Каурыйсыз канатларын җилпеп, көч-хәл белән оча...

— Коштай, безнең Коштай! — дип елап җибәргән әби.

Әби белән бабай торнаның кунак кыз Коштайга әверелгән булуын шунда гына аңлаганнар. Үзләрендә калдыра алмауларына үкенеп бетә алмаганнар.

— Коштай, Коштай! Китмә, китмә!

Ләкин торна соңгы тапкыр кычкырган да кояш баешы ягына очып югалган.

?! **1.** Әкиятне өлешләргә бүлик: ул — бабай яхшылыгы һәм торна яхшылыгы турында.

Тагын нәрсә турында?

?! **2.** Бабай яхшылыгы турында сөйләгез. Ул өлешкә исем бирегез.

3. Торна яхшылыгы турында сөйләгез. Икенче өлешкә дә исем уйлап табыгыз.

4. Өченче, дүртенче өлешләргә исем уйлап табыгыз.

5. Әкияттәге эпизодларны табыгыз.

6. Вакыйга әкиятнең кайсы җирендә бетә?

Хәрәкәт тизлеге

Хәрәкәтнең тагын бер сыйфаты — тизлеге белән танышыйк.

Җил әкрен исә, куәтле исә. Ат тиз чаба, әкрен бара. Кыз бала әкрен генә әйтә, тиз сөйли. Җил искәндә, камыш салмак кына чайкала, тиз чайкала...

Кешенең бик тиз эшләвенә халык, *ут өереп эшли*, дип бәя бирә. Кушкан йомышны тиз үтәүчегә, яратып, *әйткән җиргә күз ачып йомганчы барып кайттың*, ди. Әкрен мыштырдаган кешегә, *аяк өсте йоклап йөрисең*, ди. Эшләми торган кешегә, *түшәмгә төкереп ятасың*, ди.

Камыш шаулавын шагыйрь Һади Такташ үзенчә сурәтли.

Мокамай

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...
Алар мәңге минем хыялымда
Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,
Карт имәннәр, калмый минем арттан,
Кая барсам, озатып барырлар...
Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары —
Андагыдай шаулый торганнар...

Һади Такташ

?! **1.** Камыш Такташның туган ягында шаулый. Тагын кайда шаулый?

2. Ни өчен Такташның туган ягында гына урман аеруча куәтле шаулый?

3. Шигырьдә *шаулый* сүзе ничәү? Дөрес җавап табу өчен, алтынчы юлдан башлап шигырьне ахырына кадәр тагын бер тапкыр укып чыгыгыз.

Чаңгы шуам

Нигә өйдә ятарга?
Барам карлы тауга мин.
Рәхәтләнеп, сөенеп,
Чаңгы шуам анда мин.

Шүрли идем башта гел,
Юньләп шуа белмәдем.
Курыкмыйча шуарга
Курка-курка өйрәндем.

Үтте инде андый чак,
Ныгыттым мин егәрне.
Беләсезме, хәзер мин
Узып шуам җилләрне.

Нәҗип Мадьяров

?! Малай башта ничек шуган?

Өйрәнгәч, җилдән дә тизрәк шуган. Тагын да тизрәк шуса, нәрсәне узар иде?

Курка-курка шуып өйрәнә торган чаңгычыны күз алдына китерегез. Ул ничек шуа? Үз тәҗрибәгезне языгыз. Сез тиз шуарга өйрәнгәнче ничек шуа идегез?

Карт белән төлке

Бер карт белән карчык яшәгән. Карт базарга барган. Күп итеп балык алган. Балыгын чанага салып, кайтырга чыккан. Шактый кайткач, юлда үлгән төлке күргән.

— Менә бәхет! Төлке тиресеннән карчыгыма җылы тун тектерермен! — дип шатланган һәм төлкене чанасына салган.

Хәйләкәр төлке юри үлгән булып яткан икән. Бабай йокымсырап барганны күргәч, балыкларны чанадан ыргытып бетергән. Аннары үзе төшеп калган.

Берзаман карт өенә кайтып җиткән. Ишеген ачу белән:

— Карчык, сиңа өр-яңа төлке тун тектерәм, иске туныңны тизрәк мичкә ыргыт, янсын! — дип кычкырган.

Төлкене алып керим әле дип урамга чыкса, ни күзе белән күрсен — төлке дә юк, балыклар да юк. Өйгә йөгереп кергән, ләкин карчыгының тунын коткара алмаган. Тун янып беткән.

?! 1. Төп персонажларны табыгыз.
2. Картка бәя бирегез.

Ә хәзер әкиятне үзебезчә язышйк.

Картны егеткә әйләндерик, ә егетне төлкенең үзеннән дә хәйләкәррәк итик.

?! Акыллы кеше ни эшли? Акылсыз эшләгәннең киресен эшли. Әкиятебезне болай башлыйк: *Беркөнне егет атын җиккән дә базарга киткән...*

Их, малайлар!

Калкавычка карый-карый,
Ике күзем ялыкты.
Тотмый калмам,
Их, малайлар,
Менә мо-о-ондый балыкны!

Кап, кап, кап, кап, балык, кап!
Кармагымны табып тарт!
Малайларны көнләштереп,
Яр башында ялтырап ят!

Калкавычым су төбенә
Бер батты, бер калыкты,
Ычкындырдым,
Их, малайлар,
Менә мо-о-ондый балыкны!



Колганы тартып чыгардым —
Шаккатырдым халыкны.
Ычкындырдым,
Их, малайлар,
Үземнән зур балыкны!

Илдар Юзеев

?! Сорау. Шигырьдә кемнәр катнаша?

Җавап. Шигырьдә катнашучылар: бик оста балыкчы малай, ике зур балык, башка малайлар...

Җавап дөресме?

Шигырьдәге вакыйганы дәвам итик.

Колганы тартып чыгардым —
Шаккатырдым халыкны...

Халыкны ни белән шаккатырып була? Зур балык капсамы, бик кечкенәсе капсамы? Балык урынына башка нәрсә (мәсәлән, киез итек, агач ботагы) капсамы? Берни дә капмасамы? Кармак өзелеп калсамы? Шуннан соң күл уртасында бер балык, башын калкытып, телен күрсәтсәме?

?! Әлеге вариантларның кайсысы ошаса, шул вакыйганы дәвам итегез.

Яңа сумка

Әнисе Айратка бик матур кап-кара сумка сатып алды.

— Дипломат ул. Чып-чын күннән эшләнгән. Андый дипломатны министрлар гына йөртә,— диде Айрат.

Ачып күрсәтте, ябып күрсәтте. Серле йозагы турында әйтте.

— Менә шушылай итеп япсаң, берәү дә ача алмый,— диде.

Ләкин яңа сумканың бер кызыклы сыйфатын ул үзе дә белмәгәндер, ахры.

Без Айрат белән күршеләр, шуңа күрә мәктәпкә көн дә бергә барабыз. Бүген дә бергә киттек.

Минем былтыргы сумкамның тавышы-тыны чыкмый. Кеше күзенә чалынмыйм дип, җилкә артына посып кына бара. Айрат сумкасының эш башка. Ул бит — яңа, кыйммәтле сумка. Уч төбендә генә йөртмәле! Яңа сумка шулай итә дә — Айрат уч төбендә әле алга болганып чыга, әле артка китеп югарырак менмәкче була: «Күрегез, сокланыгыз, әнә мин ничек матур!» — ди. Ләкин балалар ул якка карамыйлар да карамыйлар. Ә яңа дипломатның башкаларны көнләштерәсе, үзенең башка сумкалардан кыйммәтрәк, шәбрәк булуын сиздерәсе килә.

Сумкага коридордан үткәндә дә игътибар итмәделәр. Класска кергәч тә, ни өчендер, күз салмадылар.

* * *

Менә дәрес тә башланды. Бераздан артта шап-шоп килгән тавыш ишетелде. Укытучы шул якка караганда, тавыш тына. Карамаса, тагын шапылдарга керешә. Башкаларның шапылдауга да исе китми. Алар ят тавышны бөтенләй ишетмәгән кебек утыралар. Классташлар ни уйлый торгандыр, ләкин мин шапылдаучыны бик яхшы беләм. Яңа сумка тавышы ул. Ачыла да шапылдап ябыла, ачыла да шапылдап ябыла. «Менә бит мин! Нигә берегез дә күреп көнләшми?!» — димәкче була.

Укытучы апа Айратны такта янына чыгарды. Сумкасын күтәрергә кушты.

— Айратның сезгә яңа дипломатын күрсәтәсе килә, балалар. Ул бит сез әйләнеп карасын дип шапылдый. Ә сез карамыйсыз да карамыйсыз. Әнә күрдегезме, нинди матур өр-яңа дипломат сатып алганнар Айратка,— диде.

Яңа сумканың шатлыгы эченә сыймады. Класста утыручылар барысы да елмайдылар, көлделәр.

«Әнә ничек шатланалар»,— дип уйлады ул.

Арада бары Айрат кына көлмәде дә, елмаймады да. Ул бөтенләй башкача уйлады. Мин дә көлмәдем, чөнки яңа сумканы кызгандым.

Альберт Гатуф

?! Мактанчык яңа сумкага сез нинди җәза бирер идегез?

Ни җитмәгән?

Искәндәр торды, юынды,—
Кулында таплар бетмәгән.
Нишләп бетмәгән дисезме?
Юынгычта су җитмәгән!

Беркөнне ул мунча керде,
Сулар анда — ләгән-ләгән!
Бите корым булып чыкты,
Ахрысы, су җитмәгән!

Иделдә су кереп чыкты,
Борыны кара, сөртмәгән.
Искәндәргә әллә инде
Иделдә су җитмәгән?..

Равил Фәйзуллин

?! «Ни җитмәгән?» шигыренең Равил абыегыз Фәйзуллин язган ахырын уйлап табыгыз. Шигырь ахырын ул ике юлга сыйдырган.

Тузганак

Мин әзлим кузгалак,—
очрады тузганак!
Башында ак бүрек,
кечкенә туп кебек!

«Тотам!» — дип үрелдем,—
ул миңа иелде.
Бүреген салды да:
«Өзмә!» — дип ялынды.

Равил Фәйзуллин

?! Автор тузганакка кеше сыйфатлары өстәгән. Шул сыйфатларны табыгыз.

Сарбай белән Ишек

Тышта чатнама суык,
Сарбай утыра туңып.
Ничек өйгә керәсе? —
Төшкән Ишек келәсе.

Әкертен генә менә
Маэмай баскычка менә.
Якын килеп янына,
Ул Ишеккә ялына:

— Тыңла әле син, Ишек,
Минем зарымны ишет:
Тышта бик нык суытты,
Тәмам аяктан екты.

Булмачы, дускай, кире,
Түгелмен ич мин бүре.
Үзем тик тә ятмыймын,
Һаман сине саклыймын.

Ачыла күр тизрәк,
Өйгә керергә кирәк!

Шыгырдады авыр Ишек:
— Әйдә инде, кара җаең.
Җебеп торма, тизрәк кер,
Ялгыш кысып куймагаем...

Резеда Вәлиева

Ишек Сарбайга яхшылык итте. Аны җылы өйгә кертте. Шигырьнең икенче өлешен уйлап

табыгыз. Икенче өлеше беренчесенең киресе булырга тиеш.

?! Беренче өлешендә Сарбайга ярдәм кирәк иде. Димәк, хәзер Ишеккә ярдәм кирәк дигән сүз.

Ул нинди ярдәм сорый?

Эт Ишек үтенечен ничек үти?

Батыр малай

Дәү әнигә килгәндә,
Ал капканы кергәндә,
Зур бер эт чыкты өреп,
Мине карак дип белеп.

Тик мин һич сер бирмәдем,
Тыштан берни сиздермәдем,
Эчтән генә шүрләдем...

Ул да якын килмәде,
Курыкты, ахры, өрмәде.
Ярый әле үзем аннан
Курыкканны белмәде...

Резеда Вәлиева

?! Автор этне шигырьдәге малайга охшата. Эт белән малай куркаклармы, батырлармы?

Каен кызы

Имәнлектә үскән бәләкәй генә Каен кызы үзенең тәүге кышын каршыларга әзерләнде. Баһадир Имән егетләре аңа суык кыш, әче бураннар, аяусыз җилләр турында күп сөйләделәр. Шуңа карамастан Каен кызының ямь-яшел күлмәген тиз генә саласы килмәде, чөнки ул аңа шундый килешә иде!

Каенкайның нәфислеген күреп сокланучылар аз булмады. Янында үскән Чыршы дусты аңа җырлар җырлады, ә Имән егетләре давыллардан саклады. Каен кызы җәй буе шулай иркәләнеп кенә үсте. Урман аша үткән юлчылар:

— Карагыз әле, карагыз! Имәннәр арасында нинди матур Каен үсә! — дип сокландылар...

Көн артыннан көн үтте, җәй артыннан ыжгырып көз килде. Усал җил, болыннардан, яланнардан ыжгыра-ыжгыра килеп, урманнарга кагылды, яфракларны коярга кереште. Төннәрен исә, болытларны куып китереп, яңгыр яудырды. Каен кызы түзде, еламады...

Янәшәдә генә үскән Имән егете, Каен кызын кызганып, аны җилләрдән ышыкларга тырышты.

Ап-ак мамык очкандай, сирәкләп кенә карлар төшкәли башлады. Каен кызы, сокланып, аларны учына алды, өреп шаярды, чәч толымнарына кушып үрергә керешге. Әмма, оныгылып никадәр генә юанырга тырышса да, барыбер өшеде. Дер-дер калтыранган Каенкайны күреп, хәтта Кыш бабай да кызганды.

Аңа ап-ак кар бөртекләре белән бизәкләп сырылган йомшак тун, кулларына бияләй, башына башлык кидерде. Ә инде бәләкәч кенә чәч толымнарына кардан тасмалар таккач, Каен кызын күреп, барысы да хәйран калды. Озын керфекләрен ап-ак итеп буяган Чыршы кызы да түзмәде:

— Син шундый сылу, ак якалы тунның үзеңә шундый килешә... Шулай да салкын кыш озакка сузылыр,— дип пышылдады.

Үсә-үсә Каен кызына яхшылыклар да, яманлыклар да күрергә туры килде. Иң коточкыч көн Яңа ел алдыннан булды. Аның дускаен — Чыршы кызын кистеләр!..

— Тотынмагыз дустыма! — дип, карлы бияләйләре белән кисүчеләрнең бүрекләренә дә бәрелеп карады, тик ярдәм итә алмады шул! Чыршы кызын чанага салып алып киттеләр... Агачлар, җырчы Чыршыны озатып, хәсрәттән башларын бөгеп калды. Каен кызының да кайгыдан башы иелде.

Берсен берсе куып, көннәр үтә торды. Кояш та нурын мулрак сибә башлады, сак кына, ипләп кенә агачларның кышкы киемнәрен салдырды. Кошлар, шат тавышлары белән урманны йокыдан уятып:

— Яз килә, яз килә,— дип хәбәр бирделәр.

Яз килде, яз!

Барча агачлар да кояш нурына үрелеп яфрак ярды, җирдә тәүге үләннәр шытып чыкты. Яшеллеккә күмелгән бу саф дөньяны кошлар яз белән котлады. Яз исә Каен кызына алкалар такты, ямь-яшелдән өр-яңа күлмәк кидерде. Каен кызының күңеле шатлык белән тулды, тик... янәшәсендә дустының юклыгы исенә төшеп күзләре яшьләнде. Шулай да ул, давыллы бураннарны җиңеп чыгуына куанып, елмаеп җибәрде.

Дилә Булгакова

?! **1.** Каен кызына ярдәм итүчеләрне санап чыгыгыз.

2. Аңа нигә ярдәм иткәннәр?

3. Ә Каен кызы аларга ничек җавап биргән? Җавапны үзегез уйлап чыгарыгыз.

Мастер

Минем әти алтын куллы,
Минем әтием мастер.
— Бүтән андый булмастыр! —
Шулай диләр күршеләр.
Чынлап әйтәм, әтиемнең
Юктыр белмәгән эше,
Ул — бик кирәкле кеше,
Ул — бик файдалы кеше!
Ул кулына алу белән,
Үтүк тә кыза башлый,
Сәгать тә йөреп китә.
Безнең ватык уенчыкны
Әти өр-яңа итә.
Телевизор, кәҗәләнсә,
Әтием кулын кетә.
Әти тиз килеп җитә:
План кора — мыек бора,
Шөребен бора аннан.
Шуны гына көткән кебек,
Сурәт чыга экраннан.
Мин һәрчак әти янында,
Уралам шунда һәр кич.
Минем дә әти шикелле
Оста буласым бар ич.

Карап тормый-нитми генә
Өйрәним ничек итеп?!
Үсим әле: кешеләрнең,
Менә ичмасам мастер, дип,
Бүтән мондый булмастыр, дип,
Торыр исләре китеп.
Бүтән мондый булмастыр, дип
Әйтү тик булмас дөрес.
Мин бит үзем генә түгел,
Абый белән икәү без.
Тагын берәү булыр, беләм.
Ансы инде — минем энем.
Алтын булыр аның кулы —
Соң, ул да бит әти улы!

Йолдыз Шәрәпова

Әйдәгез, шигырьне, беркадәр кыскартып, үзгәртә төшеп, үзебез дәвам итик. Мәсәлән, болай башлыйк: *Әти көн дә безнең уенчыкларны төзәтә. Көн дә телевизорны көйли. Безнең әти алтын куллы. Без дә әтинең уллары, шулай булгач, билгеле инде, без дә алтын куллы...*

Кирәгемне бирсәнә

Аңламассың тиз генә
Безнең әбинең телен.
Беркөнне ул кирәгемне
Бирмәкче иде минем.

Гаеп үземдә, билгеле,
Уеннан бик соң кайттым;
Сарыкларны, бәтиләрне
Абзарга да соң яптым.

Карамаганны сизеп,
Алар бакчага кергән.
Бәрәңге, суган, кишерне
Тәмам таптап бетергән.

Моны белгәч, әбием
Орышты да соң мине.
Аннары вәгъдә бирде
Бирергә кирәгемне.

— Әби,— дидем, — мине әрләп,
Бозмачы йөрәгеңне,
Миңа велосипед кирәк,
Бирсәнә кирәгемне!

Йолдыз Шәрәпова

?! Әби вәгъдәсендә торган. Ләкин оныгы һаман велосипедта йөрми. Минем ул велосипедны күрәсем дә килми, дип әйтә, ди. Нигә йөрми? Нигә велосипедны яратмый?

Оча торган тиен

Мөбарәк яши торган авыл бик матур. Авыл янында гына карурман шаулый. Урманда тиеннәр, көртлекләр, төлкеләр очрый.

Менә Мөбарәк, мылтык асып, урман буйлап бара. Тирә-якта кошлар сайрый. Кайдадыр саескан чакылдый. Тиеннәр сызгыра. Сукмак буйлап, чаштыр-чоштыр яфраклар кыштырда-

тып, керпе йөри. Сукмак янында бөгәрләнеп елан йоклап ята. Бөтен урманны яңгыратып, тукран тукылдый.

Шулчак нарат башыннан тиен атылды.

Бу — оча торган тиен. Аның алгы тәпиләре астында канат сыман ярысы бар. Сикергән вакытта, ярылар канат шикелле җәелеп китә. Оча торган тиен бик ерак араны шулай сикереп-очып уза ала. Нәкъ кош кебек.

Тиен нараттан имәнгә таба очты.

Шундый матур очып бара иде! Әйтерсең лә беркет!

Мөбарәк тиз генә мылтыгын иңеннән алды да тиенгә атты.

Урман селкенеп куйды!

Тукран тукылдавыннан туктады. Саескан тавышы тынды. Йоклап ятучы елан сискәнеп уянды да тиз генә үләннәр арасына кереп шылды. Агач башындагы каргалар, шомлы кычкырып, дәррәү күтәрелделәр. Төнен ауда йөреп арыган мәче башлы ябалак та куркып уянды. Ул-бу булмагае дип, бер агачтан икенчесенә күчеп утырды.

Тиен, очып барган җиреннән кинәт чайкалып, таш кебек аска томырылды. Ул, агач



ботакларына бәргәләнә-бәргәләнә, Мөбарәк басып торган сукмак өстенә килеп төште. Төште дә тыпырчына башлады. Мөбарәк

йөгереп килеп җитте. Тиеннең канаты яраланган иде.

Мескен тиен, Мөбарәктән качарга тырышып, үлән арасына китәргә азаплана. Тәпиләре нептечкә, үзе дер-дер калтырый. Тиен, үтерсәң үтер инде дигәндәй, сыртына ятып бәләкәй аучыга карады. Мөбарәк бу караштан куркып китте. Тирә-якта берәү дә юк. Берәрсе качып кына карап тормадымы икән? Кеше күрсә, ни оят! Ни оят!

Мөбарәк тиенне кулына алды. Тиен чыелдый. Үзе, ни эшләтерсең икән дигәндәй, Мөбарәккә карый.

Мөбарәк яраланган тиенне чыршы ботагына куйды. Бәлки, терелер, ярасы төзәлер әле. Ядрә сөягенә тимәгән, канат ярысын гына ертып киткән. Җөйләнер әле, җөйләнер!

Шул көннән соң Мөбарәкләр урманында бер генә тиен дә калмаган, барча тиеннәр бу урманны ташлап киткәннәр, ди.

Рабит Батулла

?! Кечкенә сунарчы ярдәмгә мохтаҗларны кызгана торган малаймы?

Аның тагын нинди уңай сыйфатлары бар?

ӘЙДӘГЕЗ, ӨЙДӘ УКЫЙБЫЗ!

Бүре белән Челән

Бүре тамагына сөяк кадалган. Шуннан ул Челән янына килгән дә:

— Тамактан сөякне тартып чыгарсаң, буш итмәм, бүләк бирермен,— дигән.

Челән риза булган. Тырыша торгач, сөякне озын томшыгы белән тартып чыгарган. Аннары Бүредән вәгъдә иткән бүләген сораган.

— Бигрәк оятсыз икәнсең! — дип кычкырган Бүре. — Озын муеныңны авызга тыкканга мин

әле бүләк тә бирергә тиешме? Муеныңны сындырмаганга рәхмәт әйт. Бүләкнең шуннан да кыйммәтрәге булмый!

Әсәр тәмамланмаган. Әйдәгез, бергәләп тәмамлыйк. Бүренең яман эшенә җәза бирик.

Мактанырга яратмый...

Мине беләсездер инде! —
Мәрдиев мин, Марат мин!
Мактарлык малай булсам да
Мактанырга яратмыйм.

Миннән дә шәп укучы юк,
«Биш»ле алдым бүген дә.
Шуңа мактанып торырга
Мин мактанчык түгел лә!

Башка малайлар шикелле,
Бәлки, мактаныр идем,
Болай да һәркем белә бит
Әйбәтлегемне минем!

Роберт Миңнуллин

?! Марат бик үзенчәлекле мактана. Ничек мактана?

Тиз йөри

Беркөнне Хуҗа Насретдин, ишәгенә атланып, су буена төшкән. Ярда көймәләрен сумалалап яткан балыкчыларны күргән. Балыкчылар сумаланы эретәләр дә көймә төбенә сибәләр, эретәләр дә сибәләр икән.

— Нигә алай итәсез? — дип сораган Хуҗа.

— Шулай итсәң, көймә тиз йөри,— дигән балыкчылар.

«Минем ишәк бик әкрен йөри, миңа да, болар кебек, сумала кайнатырга кирәк»,— дип уйлаган Хуҗа. Шулай эшләгән дә. Тиз генә

өенә кайткан да бер чиләк кайнар сумаланы ишәгенә сипкән... Шуннан ишәк, чыннан да, бик тиз чабып киткән.

— Балыкчылар дөрес әйткәннәр икән,— дип шатланган Хуҗа Насретдин.— Кара теге ялкауны, ничек чаба!

Ләкин ишәк ерак китә алмаган — үлгән.

?! Бер үк гамәлнең (хәрәкәтнең) ни өчен яхшы да, начар да булуын әйтегез.

Малай белән бабай

Малай бабайны тоткан,
Бабай малайны тоткан.
Малай чагын оныткан.
Бабай малай булырмы?
Мин әйтәм: алай булмас,
....
Ә бабай малай булмас.

Илдар Юзеев

?! Төшеп калган юлны табыгыз.

Әсәр төзелешен табу өчен, аны башта өлешләргә бүләләр, аннан соң, охшаганнарын кушып, икегә генә калдыралар.

Кошлар бәхәсе

Бервакыт каргалар, сыерчыклар, күгәрченнәр ятьмәгә эләккән.

«Бу бәладән ничек котылырга?» — дип уйлашканнар кошлар. Уйлый торгач, акыллы фикергә килгәннәр:

— Барыбыз да бергәләп канат җилпесәк, ятьмәне күтәрә алабыз, — дигәннәр.

Шулай иткәннәр дә: ятьмәне күтәреп очып киткәннәр.

Кош аулаучы алар артыннан чапкан. «Кош-корт тату яшәми ул, бер егылып төшәрләр әле»,— дип уйлаган.

Башта кошлар ятьмәне бердәм тартканнар. Бераздан бәхәс кузгалган:

— Ятьмәне без генә күтәреп очабыз. Без дә сезнең кебек ялкаулансак, әллә кайчан егылып төшкән булыр идек,— дигәннәр каргалар.

— Мактанмагыз. Без сездән дә күбрәк тырышабыз,— дигәннәр күгәрченнәр. Бәхәскә башка кошлар да кушылган. Талаш-тарткалаш башланган.

Дуслык беткән җирдә эш барамы?! Кошлар, бер-берсенә үч итеп, тырышмый башлаганнар. Канатларын иренеп кенә селкегәннәр.

Аскарак төшкәч, аучы, ятьмәне бавыннан тартып, кошларны җиргә төшергән.

Ә аннан соң... Аннан соң барысын да читлеккә ябып куйган.

?! Бу әкият аучы, ятьмә, кошлар турындамы, аучы белән кошлар турындамы, әллә кошлар турында гынамы?

Кошларны сөйләргә өйрәтүче кеше — автор. Шул кошлар мисалында автор безгә ни әйтә?

Әкият яратучы патша

Борын-борын заманда булган, ди, бер патша. Ул бик тә әкият яраткан, ди. Көннәрдән бер көнне патша хәбәр салган: «Кем дә кем мине әкият сөйләп туйдыра ала, шуңа бик күп байлык һәм ярты патшалыгымны бирәм»,— дигән.

Бер бик тапкыр егет көчен сынамакчы булган, ди. Патша янына рөхсәт сорап кергән дә әкиятен сөйли башлаган:

— Борын-борын заманда булган, ди, бик саран бер патша. Бу патшаның байлыгы бик күп булган, ди. Шулай беркөнне патша амбар салырга осталар чакырткан, ди. Амбарны салып та куйганнар. Әмма бер генә урында чыпчык сыярлык кына тишек калдырганнар.

Амбарга бодай тутырганнар. Шуннан соң Җир йөзендәге бөтен чыпчык җыелып килгән, ди. Җыелып килгәннәр дә берәмләп бодай ташый башлаганнар. Менә беренче чыпчык бодай алып чыккан, менә икенчесе, өченчесе...

Әкиятче шулай патшаны өч көн, өч төн тыңлаткан, ди. Патша түзмәгән: «Азагы кайчан?» — дип сораган. «Тукта әле, берәмләп

бодай ташу майлы бәрәңге ашау түгел ул, — дигән егет. — Аның азагы кызык әле».

Шулай чыпчыклар чиратлашып бодай чүпләгәннәр, ди. Дүрт көн, дүрт төн вакыт узган. Атна тулгач, патша: «Кайчан азагы була?» — дип сораган. «Тукта, анда бодай бик күп бит әле»,— дигән егет. Тагын бер атна үтеп киткән. Патша тәмам арыган. «Җитәр, тукта, кирәкми миңа чыпчыкларың!» — дигән.

Шуннан ярты патшалыгын һәм бик күп байлыгын егеткә бирергә мәҗбүр булган, ди.

?! Әкиятнең бер өлеше егетнең әкият сөйләве турында. Икенче өлеше нәрсә турында?

Шалкан

Бер бабай шалкан утырткан. Шалкан бер көн үсәсен бер сәгатьтә үскән, бер ай үсәсен бер көндә үскән. Үскән дә үскән. Бик зур булган. Аны алыр вакыт җиткән.

Бабай тарткан, тарткан, тартып чыгара алмаган. Ярдәмгә әбине чакырган.

Икәүләп тартканнар, тартканнар, тартып чыгара алмаганнар. Кызлары ярдәмгә килгән.

Бергәләп тартканнар, тартканнар, өчәүләп тә тартып чыгара алмаганнар...

?! **1.** Әкиятне үзегез дәвам итегез. Ярдәмгә тагын кемнәр чыга ала? Алар ни эшлиләр?

2. Әкияткә башка исем уйлап табыгыз.

3. Әкиятне ике генә өлешкә калдырыгыз.

4. Әкияттә шалканга бабай бәйләнгән... Ничек бәйләнгән?

5. Бабайга — әби... Шул күп бәйләнештән иң әһәмиятле ике бәйләнешне табыгыз.

Әби әкияте

Моннан берничә ай элек, кышкы салкын көннәрнең берсендә, Казанга Рөстәмнең әбисе килде. Аның килүен Рөстәм түземсезләнеп көтте. Кадерле кунакның кайчан килергә җыенуын ишеткәч тә, Рөстәм календарьда билге ясап куйды һәм көн саен иртә белән:

— Тагын биш кенә көн калды, тагын дүрт кенә көн калды!..— дип әйтә торды.

Әби календарьда билгеләнгән вакыттан бер көн элек килде. Рөстәм моңа шатланды. Әбисен ул каршы чыгып алырга теләгән иде. Ә әби Рөстәм югында килеп төште.

Шәфкатьле әбисен Рөстәм элек-элек тә күргән иде. Үткән елны ул бөтен җәйне аның белән бергә авылда уздырды. Ләкин ул чакта әби дә, Рөстәм үзе дә, әллә ничек, бер-берсен аңламыйлар, сөйләргә сүз тапмыйлар иде. Ә хәзер... хәзер бөтенләй башка... Рөстәм дәресләрен хәзерләп бетерүгә, әби аңа һәр кич төрле-төрле көйләр җырлап җибәрә. Рөстәм башта әбинең җырлау рәвешен генә ярата иде, хәзер, ияләшкәч, аның көйләрен дә ярата. Моңлы итеп җырлый ул!

Шундый күңелле әбиеңне ничек яратмыйсың ди. Ярата, бик ярата Рөстәм аны! Ашка яки чәйгә утырганда, Гайшә апа беренче тарелканы, беренче чынаякны балага куя иде.

— Әбигә, әүвәл әбигә! — дип кычкыра башлады Рөстәм.

Ярата, бик ярата Рөстәм аны! Хәтта ул мәктәп буфетыннан алынган конфет, прәннекләрдән дә аңа өлеш чыгара. Ә әкиятләре ни тора әбинең! Нинди матур сөйли ул аларны... Тыңлап туйгысыз! Андый әкиятләрне Рөстәмнең китапларда да укыганы юк әле.

* * *

Кышкы кичләрнең берсе иде. Гайшә апа белән Һашим абый академия театрына спектакль карарга киттеләр. Өйдә Рөстәм белән әби генә калды. Шул кичне Рөстәм яңа әкият тыңлады. Әби аны бик тәмләп, бик озын итеп сөйләде. Аның кыскача эчтәлеге болай иде:

Абага — карап торырга гап-гади үсемлек. Исе дисәң — хуш исе юк, яфрагы дисәң — яфрагы да әллә ни түгел. Ләкин шул абаганың искиткеч бер хикмәте бар.

Абага чәчәк атмый, диләр. Ялганлыйлар! Ата икән. Мең вә миллион абагалар арасында бер абага очрый, ди. Менә шушы күп абагалардан сирәк очрый торганы яз көне, җиде төн уртасында, ике-өч секундка чәчәк ата, ди. Ул чәчәк атканда яшен яшьни, күк күкри, җенпәриләр чыга, кара урман яктыра, ди. Бу вакыт абага шундый матур була, ди, аның йолдызлардай атып торган чәчәкләреннән күзләр чагыла, ди, аннан таралган хуш истән башлар әйләнә, ди.

Абага чәчәген өзеп, телләре астына кыстырырга өлгергән кешеләр кеше күзенә күренмәс хәлгә киләләр, ди. Дөньяда тереклек булганнан бирле, тылсымлы абага чәчәген өзеп, кеше күзенә күренмичә йөрергә теләүчеләр бихисап күп булган, ди. Ләкин андый абаганы табуы кыен икән. Кайберәүләр, илдән илгә йөреп, бөтен гомерләрен әнә шундый абаганы эзләп уздырганнар.

Гадел Кутуй

?! Сез абага чәчәген табып тел астына кыстырдыгыз, ди. Күренмәс хәлгә килгәч, иң башта ни эшләр идегез?

Аннан соң ниләр эшләр идегез?

Яз

Сикереп-сикереп ага кар суы.
Кар суының тибенеп ярсуыннан
Гөрләвекләр уйный, котыра,
Челтәрләнеп карлар сүтелә,
«Челтер-челтер» көлеп боз кителә,
Нурлар, ахры, кытыгын китерә.

Муса Җәлил

?! **1.** Шигырьдә яз килүнең тәртибе үзгәргән. Төзәтеп, үз сүзләрегез белән әйтегез.

2. Авторны беренче юлда күрәбез: су сикерми бит, ә ул суны кешеләр кебек, песиләр кебек сикерә ди. Автор тагын кайсы юлларда күренә?

3. Шигырьне ятлагыз.

Шәп егет

Кайткан чакта кинодан,
Артыграк уйнаган.
Сәгать кичке ун тулган,
Өй эше гел онтылган.
Мәктәп төште исенә,
Торгач кына йокыдан.

Бүген баргач мәктәпкә,
Укытучы, әлбәттә,
Сорар аннан дәресен.
Әйтеп биргәч дөресен,
Апалары, билгеле,
Куяр «бик шәп» билгене.

Менә шул!

Хәзер уйлый:
«Мин кичен
Эшләргә дип өй эшен,
Өйгә тизрәк ашыксам,
Аннан урамга чыксам,
Абыйга да берочтан
Кар көрәргә булышсам,
«Биш»ле дә алсам бүген,
Шәп егет булыр идем,
Һәм, үземне кызганып,
Йөрмәс идем кызарып».

Менә шул!

Фәннур Сафин

?! **1.** Шигырьне сәхнәдән укыган кебек матур итеп укыгыз.

2. Шигырьнең баштагы өлеше ялкау малай турында. Малайны ни өчен ялкау дибез? Аңлатыгыз. Шигырьнең икенче өлешендә бала эшчәнме?

Сүз тыңлаучан малай

Бер малай, ат белән юлдан барганда, энә тапкан. Энәсен арбасына салган. Кайткач, анасына кереп әйткән:

— Әни, мин сиңа энә табып кайттым,— дигән.

— Энәң кайда соң?— дип сораган анасы.

— Хәзер алып кереп бирәм,— дигән улы. Чыгып арбасыннан эзләсә, анда берни дә юк, ди. Анасына әйтә бу:

— Мин аны арба төбенә салган идем, әллә кая киткән,— ди.

Анасы әйткән:

— Әй җүләр, энәне арбага салалармыни, түшкә кадыйлар аны,— дигән.

Икенче вакыт юлдан барганда, малайга зур кадак очраган. Кадакны алган да бу, бишмәтенең якасын тишеп, кадап куйган. Кайткач, анасына әйткән:

— Менә, әни, бу юлы син әйткәнчә эшләдем, югалтмадым,— дигән.

?! **1.** Мәзәкнең баштагы өлешендә малай ялгыша. Ничек ялгыша?

2. Мәзәкнең икенче өлешен сөйләгез. Бу юлы ул әнисе кушканны эшләде. Ләкин барыбер ялгышты. Ничек ялгышты? Нишләп ялгышты?

Елның дүрт фасылы

Боз һәм кар эрде,
Сулар йөгерде,
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.

Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт?—
Йә, әйтеп кара.

(Яз)

Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште,
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.

Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура,—
Бу кайчак була?

(Җәй)

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява,
Җирләр дымлана,—
Бу кайчак була?

(Көз)

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган,
Уйный җил-буран,—
Бу кайчак, туган?

(Кыш)

Габдулла Тукай

?! **1.** Бу шигырьдә катнашучылар күп. *Боз, су, елга...* (Дәвам итегез.)

2. Биредә шигырьне язучы — автор үзе дә катнаша әле. Ул күренеп тора диярлек. Әнә бит ул, безгә туп-туры карап, сораулар яудыра. Үзе безгә сораулар бирә, ә үзе: «Бу сорауларга җавапны сез, әлбәттә, беләсез. Шуңа күрә җавапларын да язам»,— ди.

Елгаларны кем елата? Башакларны кем пешерә? Шигырьне язучы — автор елата. Башакларны да ул пешерә. Үзе безгә: «Елга елыймы? Ашлык мичтә пешәме?»— дип, ишетелер-ишетелмәс кенә сораулар бирә. Шундый сораулары белән автор безгә әсәрдәге урынын күрсәтә.

Карга хәйләсе

Бер карганың, кырда йөри торгач, эчәсе килде, ди. Якын-тирәдә бер дә су булмаган. Карга уракчылар янына киткән. Анда кешеләрдән ераграк бер комган белән су бар икән. Тик комганы гына биек, ди. Өстенә менеп, муенын сузып караган. Суы төбендә генә икән,

буе җитмәгән. Кереп эчәргә комган авызы тар икән. Комганны аударса, суы түгел». «Эчми калырмын»,— дип уйлаган. Байтак йөри торгач, моның исенә төшкән. Вак таш җыеп эченә тутырган. Комган таш белән тулган. Су күтәрелгән. Карганың буе җитәрлек булгач, карга рәхәтләнеп утырып эчкән. Шушылай, дустларым, кайчагында көч җитмәслек нәрсәне акыл белән алырга була.

?! Автор күренеп диярлек тора. Шуны исбат итегез.

Сыйныфташлар

Беренче сыйныфка йөри
Укучы кыз Диана,
Йоклап калмыйм тагын, диеп,
Таң атуга уяна.

Бик әйбәтләп юына да
Чәчләрен тарап куя,
Китапларын, дәфтәрләрен
Яңадан барлап куя.

Җитез генә ашап алгач,
Җәһәт кенә киенә,
Ул арада кереп җитә
Сыйныфташы Алинә.

Әй серләшәләр икәүләп,
Чырык-чырык көләләр,
Соңга каласыз бит, дигәч,
Тиз чыгып йөгерәләр...

Флёра Тарханова

?! **1.** Диана мәктәпкә ничек җыена?
2. Мәктәптән кайткач, ул нәрсәләр эшләр? Дәфтәрләрегезгә языгыз.

Тышлыктагы рәсемнәр белән танышыйк

?! **1.** Дәреслектәге рәсемнәрне аңлатыгыз. Тышлык рәсемендәге балалар нишлиләр?

2. Сез андагы малай урынында булсагыз нишләр идегез?

3. Андагы кыз урынында булсагыз нишләр идегез?

?! Тышлыкның эчке ягындагы беренче рәсемдә малай тауга менә. Нигә менә? Билгеле инде, шуып төшәр өчен менә. Икенче рәсемдә таудан төшә. Чаңгы эзенә карап, малайның ничек һәм ни өчен төшүен әйтегез.

?! Тышлыкның эчке ягындагы өченче рәсемгә карагыз. Монда да тау күрерсез. Бу юлы тау тауга охшаган. Ләкин, болытка терәлсә дә, тәбәнәк. Тәбәнәк, чөнки малайны рәссам зур итеп ясаган. Тау биек булырга тиеш иде. Рәссам, мөгаен, биек тауга менүче малай егылып төшәр дип курыккандыр.

Тауны биек итеп рәсем ясагыз. Кәгазь битенә биек тау сыймыймы? Сыя. Тауны биек

итеп төшерү өчен, аңа менүчене кеп-кечкенә итеп ясарга кирәк. Рәсемегезне шулай ясагыз.

Беренче рәсемдә сез ясаган бик биек тауга менгән малай шатлана! Ник шатланмасын, биек тауга менү авыр да, куркыныч та бит. Ә ул курыкмаган, менгән. Икенче рәсемдә малай шакката. Шаккатарлык та шул. Бәләкәй генә кыз бернинди җайланмасыз-нисез тау башына йөгергән дә менгән.

Алай була алмый, диярсез. Була ала, ди безгә рәсем авторы. Рәсем — әдәби әсәр кебек бит ул. Рәсем эчтәлеген монда да автор үзе уйлап чыгара. Ул болай уйлый: кечкенә кыз малайның тәвәккәллегенә, батырлыгына сокланып карап торган. Шулкадәр сокланган, чәчәк бирү өчен, тауга ничек йөгереп менүен үзе дә сизми калган. Соклану, ярату хисе барын да җиңә. Мин шуңа ышанам. Рәсемгә шул ышанычымны төшердем, ди автор.

ЭЧТӘЛЕК

ӘСӘРДӘ КАТНАШУЧЫЛАР

Бәхетле бала. *Габдулла Тукай* 3
Гали белән Кәҗә. *Габдулла Тукай* 4
Гөлнар мәктәпкә бара. *Мәрзия Фәйзуллина* 5
Кара тавык, ак тавык. *(Мәзәк)* 7
Балкый фонтан. *Нәҗип Мадьяров* 8
Мәкальләр 9
Макай белән Акбай. *Илдар Юзеев* 9
Тукта! Ник качасың? *Илдар Юзеев* 10
Җиңү. *Йолдыз Шәрәпова* 12
Карандаш белән Бетергеч. *Альберт Гатуф* 16
Тәнкыйтьлиләр. *Нәҗип Мадьяров* 18
Табышмаклар 19
Салкын аваз. *Шәүкәт Галиев* 20
Үсми калган хәреф. *Роберт Миңнуллин* 21

ӘЙБЕР СЫЙФАТЛАРЫ

Күз. *Габдулла Тукай* 22
Гали. *Дәрдемәнд* 23
Зәңгәр күл. *Бари Рәхмәт* 24
Чебиләр. *Мәхмүт Хөсәен* 26

СҮЗ СЫЙФАТЛАРЫ

Такмаклар, үртәвечләр 29

Сүз эчендә сүз

Чагу. *Шәүкәт Галиев* 38
Таяк. *Шәүкәт Галиев* 38
Карлы-карсыз карбыз. *Роберт Миңнуллин* 39
Ачык авыз. *Роберт Миңнуллин* 39
Алма. *Роберт Миңнуллин* 40
Айлы малай, айлы бабай. *Роберт Миңнуллин* 40

КҮРЕНЕШ СЫЙФАТЛАРЫ

Тугайга чыклар төшкән. *Сибгат Хәким* 41
Дим буенда. *Садри Җәләл* 43
Туган җир. *Сибгат Хәким* 46

ХӘРӘКӘТ СЫЙФАТЛАРЫ

Җир йокысы. *Габдулла Тукай* 49
Эш. *Шәүкәт Галиев* 50
Чабалар. *Шәүкәт Галиев* 53
Алма, пеш! *(Мәзәк)* 53
Буран. *Гомәр Толымбай* 56
Китап һәм балалар. *Мәҗит Гафури* 57
Шөпшәләр. *Гасыйм Лотфи* 57
Чүкеч. *Габделхәй Сабитов* 60
Яхшылыкка — яхшылык. *(Әкият)* 65

Хәрәкәт тизлеге

Мокамай. *Һади Такташ* 72
Чаңгы шуам. *Нәҗип Мадьяров* 73

Карт белән төлке. *(Әкият)* 74
Их, малайлар! *Илдар Юзеев* 75
Яңа сумка. *Альберт Гатуф* 77
Ни җитмәгән? *Равил Фәйзуллин* 80
Тузганак. *Равил Фәйзуллин* 81
Сарбай белән ишек. *Резеда Вәлиева* 81
Батыр малай. *Резеда Вәлиева* 83
Каен кызы. *Дилә Булгакова* 84
Мастер. *Йолдыз Шәрәпова* 88
Кирәгемне бирсәнә. *Йолдыз Шәрәпова* 90
Оча торган тиен. *Рабит Батулла* 91

ӘЙДӘГЕЗ, ӨЙДӘ УКЫЙБЫЗ!

Бүре белән Чеűлән. *(Мәсәл)* 95
Мактанырга яратмый... *Роберт Миңнуллин* 96
Тиз йөри. *(Мәзәк)* 97
Малай белән бабай. *Илдар Юзеев* 98
Кошлар бәхәсе. *(Әкият)* 99
Әкият яратучы патша. *(Әкият)* 101
Шалкан. *(Әкият)* 102
Әби әкияте. *Гадел Кутуй* 104
Яз. *Муса Җәлил* 108
Шәп егет. *Фәннур Сафин* 108
Сүз тыңлаучан малай. *(Мәзәк)* 110
Елның дүрт фасылы. *Габдулла Тукай* 111
Карга хәйләсе. *(Мәсәл)* 112
Сыйныфташлар 113
Тышлыктагы рәсемнәр белән танышыйк 115

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 1 класса четырёхлетней
начальной татарской школы

Издание 2-е, дополненное

Казань. Издательство «Магариф». 2009

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
1 нче сыйныфы өчен дәреслек

Тулыландырылган 2 нче басма

Редакторы *Р. И. Раскулова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда
биткә салучысы *М. И. Данилевская, Г. Г. Камалова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе
Э. Ф. Нурмөхәммәтова
Корректоры *С. З. Гыймалетдинова*

Форматы 70×90 1/16. Офсет кәгазь.
«Букварная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 8,78 + форз. 0,49.
Нәшер-хисап табагы 4,62 + форз. 0,49. Тиражы 3300 д. Заказ В-214.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru
http://www.magarif.com

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.



ISBN 978-5-7761-1930-9